OMEGA OFFICIAL TIMEKEEPER
КӨН СӘГАТЬ МИНУТ СЕКУНД
2015 ЕЛГЫ СУ СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА 16 НЧЫ ФИНА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫНА КАДӘР



# БРОНТЕ КЭМПБЕЛЛ – ИРЕКЛЕ СТИЛЬ БЕЛӘН 100 МЕТР ДИСТАНЦИЯГӘ ЙӨЗҮ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ

07.08.2015, 17:40
СПОРТ

**Бу минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында бүгенге көннең беренче финал йөзеше тәмамланды. Ирекле стиль белән 100 метр дистанциягә йөзү буенча дөньяның иң көчле 8 спортчысы ярышты.**

Пьедесталдагы урыннар берьюлы ике австралияле йөзүчегә эләкте – алар апалы-сеңелле Кэмпбеллар. Алтын медальне Бронте Кэмпбелл яулады, ул дистанцияне 52.52 күрсәткече белән үтте. Аның артыннан финишка швед йөзүчесе Сара Шострем килде, аның күрсәткече – 52.70. Призлы өчлекне Кейт Кэмпбелл япты, аның күрсәткече – 52.82.

ДЧ-2015. Йөзү

Хатын-кызлар. Ирекле стиль. 100 м.

1. Бронте Кэмпбелл (Австралия) - 52.52

2. Сара Шострем (Швеция) – 52.70

3. Кейт Кэмпбелл (Австралия) – 52.82

7 август. Казан. "Казан Арена"

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА